Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге составына керүче Түбән Чаллы торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елның 16 ноябре № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Түбән Чаллы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак авыл җирлеге Түбән Чаллы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатынннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче солдатлардан тыш, 2025 елда 7700 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны:

– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
– Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү;
– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен ремонтлау;
– халыкның күпләп ял итү урыннарын (паркларны, скверларны, яр буйларын, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кызыл Чапчак авыл Җирлеге башлыгы Б.В.Ильдарханов